Әхмәдгалиева Гүзәлия Гәбдрәүф кызы
ф.ф.к, өлкән укытучы

# ИНТЕРНЕТ БАСМАЛАРДА СӨЙЛӘМ СТИЛЕ

Хәзерге көндә татар теленең, дөньяның башка телләре кебек, интернетта куллану үзенчәлекләре күп кенә телче галимнәр тарафыннан өйрәнелә. Тел иясенең үзгәрүе дөньяның виртуаль картинасын чагылдыра торган телнең үсеше белән бертигез бара. Булган кыйммәтләрнең күзгә күренеп үзгәргәне күренә: компьютер куллану белеме тел белеменә караганда өстенрәк куела, шуңа күрә гадәти аралашу кагыйдәләренә каршы килгән гадиләштерелгән телдә сөйләшү аерым дәрәҗә булып санала.

Бүгенге көндә Интернетның элегә кадәр билгеле булган иң зур мәгълүмат чыганагы булып торганын һәркем кабул итә. Ләкин аның оперативлык, тизлек һәм куллану уңайлыгы кебек мөмкинлекләре танып белү өчен генә түгел, ә аралашу чарасы буларак та бик рәхәт кулланыла алганын күрсәтә.

Виртуаль дөньяда һәрбер теләгән кеше коммуникацияне җиңеләйткән, психологик киртәләрне бетергән һәм «мин»нең иҗади мөмкинлекләрен иреккә чыгарган маска киеп куя. Шәхеснең үз-үзен тормышта белдерү өчен барлык мөмкинлекләр дә ачык: барлык төр чатлар, форумнар, электрон почта, телеконференцияләр һ.б. Аларның бер мизгел эчендә җавап бирүе һәм юкка чыгуы аралашуны җиңеләйтә һәм нәтиҗәләр өчен җаваплылыкны киметә яки, гомумән, бетерә.

Интернет дөньясындагы яңа тормыш стиленә аралашу өчен яңа тел чараларын чыгару яки искеләрен үзгәртү таләп ителә башлады. Мәсәлән:

- Интернет кулланучылары чыгарган сленг гомумкулланылыш лексикасына күчә;
- эпистоляр жанрның электрон хатлар аша хәбәрләшү рәвешендә әйләнеп кайтуы шулай ук үз тел үзенчәлекләренә ия;
- виртуаль пространствоның уен белән беррәттән баруы коммуникациянең уенга охшый башлавында күренә, моның аркасында бик житди Интернет сәхифәләрендә кулланган тел дә сөйләмә стильгә тартым була.

Интернетның барлыкка килүе текст статусының үзгәрүенә китерә. Аеруча чатлар кебек аралашу урыннарында иҗади ягы белән ачылып киткән кеше текст кебек, хәтта аннан да зуррак әһәмияткә ия була башлый. Моннан тыш, чатта аралашучылар тембр, әйтелмәнең бер өлешен ассызыклау, эмоциональ төсмер, тавыш көче, дикция, ишарә һәм мимика кебек сөйләмдә кулланылган өстәмә тәэсир чараларыннан тулысынча диярлек мәхрүм калалар. Шуның аркасында сөйләмнең ышандыру дәрәҗәсен түбәнәйтә, чөнки, психологлар фикеренчә, гадәти аралашу вакытында вербаль булмаган коммуникациянең өлеше 55%ка кадәр җитәргә мөмкин.

Мондый зур күләмдәге югалтуны күпме генә булса да тутырыр өчен Интернетта аралашуга өстәмә чаралар өстәлмичә калмый. Беренче чиратта,

"эмоциональ дефицит"ны тулыландару максатыннан, виртуаль текстка өлешчә типиклаштырылган хис-кичереш күрсәткечләре – "смайлик"лар (инглизчәдән smile – елмаю) бик мул кертелә. Моңа карамастан, алар да хис-кичерешнең ясалма формасы булып тора. Тембр югарылыгын һәм әйтелмәнең бер өлешенә акцент ясалганын билгеләү өчен виртуаль аралашуда еш кына "капс" (инглизчәдән "Caps Lock" – клавиатураның югары регистрын беркетү төймәсе), ягъни зур хәрефтән язуны да куллану күзәтелә. Челтәрдә әлеге ишарә тавышны күтәреп әйтү дип аңлашыла һәм игътибарны җәлеп итү чарасы буларак хезмәт итә.

Виртуаль чынбарлыкның төп яңалыгы – кешеләр мөнәсәбәтенең шартларын үзгәртү, бу үзенчәлек тел дәрәҗәсендә дә чагылмыйча калмый. Тышкы дөньяга турыдан-туры бәйләнгән Интернет даирәсе кешеләрнең актив эшчәнлегенә таянып кына тормыш итә ала. Аны кешенең реаль, тере фикерләвенең текстлар формасында чагылышы дип күз алдына китереп була. Аның эчендә сүз белән белдерелгән әйтелмәләрдән тыш төсләр, тавыш, графика һәм анимация берләшеп китә.

Лингвистик яктан караганда, текстологиядә яңа күренеш – Интернетның тел даирәсен оештырып торган гипертекст төшенчәсе турында сүз бара. Гипертекст – ул телдә чагылган яңа үзенчәлекле фикерләү ысулы. Ул төрле күпсанлы үзгәрешләргә, күчерүләргә һәм эчтәлеген күп ысуллар белән интерпретацияләүгә ачык. Аның эчендәге гиперсылтамалар мәгълүматны өлешләп төзергә мөмкинлек бирәләр, шуның аркасында алар бер-берсенә тыгыз бәйләнгән һәм шул ук вакытта бер-берсеннән чагыштырмача бәйсез. Интернет кулланучыларның даими рәвештә мөрәҗәгать иткән тел чараларына игътибарларын активлаштыра. Моннан тыш, виртуаль шәхесләр аралашуда даими кулланылган яңа вербаль һәм вербаль булмаган чараларның беренче авторларына әверелә баралар. Шуның аркылы алар виртуаль даирәне генә түгел, ә аның эчендә җәмгыять кулланган телне оештыруда катнашалар.

Гади сөйләм теле традицион рәвештә әдәби телнең сүздән таралган формасы булып исәпләнеп килгән иде, ләкин Интернет шартларында кулланылган телдә әлеге стильнең күп характерлы үзенчәлекләре чагылыш таба, ләкин барысы да язма рәвештә теркәп барыла. Мәсәлән:

- әзерләнмичә сөйләшү;
- бер линиягә тезеп әйтү сөйләм чараларының экономиясенә дә, артыклыгына да китерә ала;
- сөйләм актының турыдан-туры баруы һ.б.

Виртуаль шәхесләр үзара реаль вакытта тудырыла барган язмача текстлар ярдәмендә генә аралашу мөмкинлегенә ия булганга, әлеге язмаларга сөйләмә телгә хас була спонтанлык билгеле бер күләмдә чагыла.

Интернетның киң кулланылыш ала баруы безнең җирлектә дә хәзерге татар телендәге процессларының активлашуына, фонетика, синтаксис, морфология, сүз ясалышы, стилистика һәм иң ачык лексика катламнарындагы үзгәрешләрнең көчәюенә китерә. Әлеге интенсификация

виртуаль даирәнең гомуми үзенчәлеге белән дә, Россиянең конкрет шартларында татар телен куллану үзенчәлекләре белән дә тыгыз бәйләнгән. Татар теле Интернетта нигездә язма вариантта яши, ләкин челтәрдәге аралашу дәвамында сөйләм темпы аның телдән барган төренә якынлаша.

Бүгенге көннәрдә телнең мөнәсәбәтләр кору өчен кулланылган яңа формасы – язмача сөйләмә тел оешып килә. Интернет сәхифәләрендә аралашу өчен кулланылган тел кулланучыларның да, аны оештыручыларның да орфографик, пунктуацион һәм стилистик грамоталылыгын ачык күрсәтә. Телче кешегә әлеге телнең лексик яктан жаргоннарга бай булуы белән, ә грамматик яктан сөйләмә тел конструкцияләрен киң куллануы белән хәзерге әдәби телдән аерылганы күзгә бәрелеп тора.

Интернет сөйләмендә аралашучыларның сөйләмә фонетика үзенчәлекләрен чагылдыру (мәсәлән, *җарар* (ярар), *әстәгемә* (әстәгъфирулла) һ. б.) киң таралган, еш кына фразаның интонацион бизәген, смайликлардан тыш, таркатып язылган сузыклар ярдәмендә (мәсәлән, *«Нәрсәәә?»; «Яраааатааааам»* һ. б.) бирергә омтылу да күзәтелә.

Интернет телендә яңа сүзләрнең барлыкка килүе ташкын рәвешендә бара. Татар теле өчен компьютерларга һәм Интернетка бәйле терминология ике юл белән бара. Беренчедән, бу өлкәгә бәйле сүзләр тәрҗемә ярдәмендә бирелә, моның аркылы элекке сүзләрнең өстәмә мәгънәсе барлыкка килә, яки татарча сүзләрдән кушып ясала. Мәсәлән: *кулланучы, төймә, сәхифә, тычкан, санак, системага керү/ системадан чыгу, серсүз, дискйөрткеч* һ. б. Икенчедән, гадәти сөйләмгә хас булганча, арадашчы вазыйфасын рус теле үти. Аның аша күп очракта инглиз теле алынмалары я турыдан-туры, ничек бар шулай кабул ителә, я төрле үзгәрешләр кичерә. Яңа сүз ясауның төп ысулы булып сүз ясагыч кушымчаларны куллану кала бирә. Гадәттә, һәрбер яңа сүзнең нигезендә инглиз теле алынмасы яки тамыр морфемасы ята, кайбер чакны аббревиатуралар да тамыр урынында кулланыла. Алга таба исә сүз я татар теленең сүз ясау кагыйдәләренә буйсына (мәсәлән, *компиляцияләү, спамлау, банлау, апгрейдлану, онлайндагы* һ.б.), я кириллицага күчкән рәвештә генә оригиналдагыча кулланыла башлый (мәсәлән, *драйвер, домен, сервер* һ. б.).

Шулай итеп, Интернет – татар теле өчен яңа куллану даирәсе. Бу өлкәдә оешып килгән телнең иң беренче төп үзенчәлекләре – аның сөйләмә стильгә таянганында. Ясалма шәхесләр исеме астына яшеренү Интернетның бөтен аралашу чараларында чагылмаса да, демократиклыкка һәм гадилеккә омтылу онлайн формада яшәгән эш кәгазьләренә дә үтеп керә һәм эшлекле язышуның стандартларын күпкә җиңеләйтә. Моннан ары, Интернет стиленең үзара аралашкан шәхесләрне максималь дәрәҗәдә якынайтканга күрә, әйтелгәннәргә ышаныч арта һәм контактны тизрәк урнаштырырга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта шәхесләрнең Интернет шартларында үз-үзләрен ирекле тотуы, психологик киртәләрнең югалуы, нәтиҗәгә, ягъни текстларны үзләштерүгә караганда аларны иҗат итү процессын өстен куюю һичшиксез яңа тел иҗатына, татар теленә булган мөнәсәбәтнең үзгәрүенә китерә.

Гомумән алганда, Интернет киң массаларның грамоталык дәрәҗәсен ачык күрсәткән чарага әверелеп китте. Билгеле булганча, грамматик һәм орфоэпик күнекмәләрнең беркетелү дәрәҗәсе спонтан, әзерлексез барган сөйләмдә ачык күренә. Интернет барлыкка килгәнче мондый сөйләм, телдән Димәк, барлык грамматик һәм стилистик хаталар, кыска вакытка булса да, язуда беркетелеп кала. «Шәхес–текст» яки «шәхес–тел» формуласы Интернетта аксиомага әверелеп китә, чөнки барлык индивидуаль сөйләм үзенчәлекләре дә күз уңында ярылып яталар. Болар барысы да телнең үсешен күрсәтәме, әллә телнең ярлылана һәм гадиләшә баруын исбатлыймы? Бу сорауга телчеләр төрлечә җавап бирәләр.

Бер яктан караганда, Интернет аркасында тизәйгән иҗтимагый үсешнең телгә турыдан-туры тәэсире һәм яңа шартларга җайлашуы турында караш бар. Икенче яктан, әлеге тенденцияләрнең тискәре йогынтылар да һәркемгә билгеле. Сөйләмгә бер яклы гына якын килү, тел чараларының нинди жанр һәм стильгә туры килүен аера белмәү күзәтелә.

Этикетка таләпләрнең бик түбән булуы аркасында әңгәмәдәшкә хөрмәт һәм игътибарлылык дәрәҗәсе төшә: кеше исемнәрен юл хәрефеннән язу, статус буенча югары эш урындагы кешегә сөйләмә стильдә мөрәҗәгать итү, тыныш билгеләрен кулланмау аркасында язуның аң агымына әйләнә баруы һ.б.

Текстны формалаштыру аксый, әйтергә теләгәннәрне җиткерү өчен иң кыска юл сайлана, төрле шаблоннар аркасында сөйләм вариативлыгы югала.

Язылганнарны орфографик һәм грамматик яктан автомат рәвештә тикшерү һәм тәкъдим ителгән форматлар ярдәмендә төзәтү мөмкинлеге кулланучыларның телне белү дәрәҗәсен киметә. Моннан тыш, хатлар еш кына тикшерелмичә генә җибәрелә.

Интернет теленә хас тагын бер үзенчәлек итеп жаргонизмнарны һәм «каты» сүзләр куллануны күрсәтергә мөмкин. Алар тексттагы оператив мәгълүматның урынын тутыралар, аңа җорлык өстәп, аудиторияне җәлеп итәләр. Бу максатка шулай ук укучыга якын тору һәм сөйләмнең ышаныч тудырган тонда баруы да хезмәт итә. Ләкин челтәрдәге текстларның иң аерылгысыз үзенчәлеге булып түбән грамоталылык кала бирә. Бик еш Интернет басмалары үзенең укучыларын аларны оештыруда катнашырга чакыралар һәм үзләренә дә мәкаләләр язырга тәкъдим итәләр. Интернет кулланучыларның бик ирекле сөйләшкәнен, ә электрон редакциянең язылганнарның барысын диярлек үткәргәнен исәпкә алсак, публикация теленең нинди булуы аңлашылырга тиештер.

Интернетта аралашучы гади кешеләр ирекле, киртәләрне кабул итмәгән һәм дөреслеге турында кайгыртырга кирәк булмаган телне үз итәләр. Алар өчен аралашу формасы түгел, ә аның асылы әһәмиятле. Әлбәттә, бу очракта тел чиста була алмый, чөнки әлеге жаргонизмнар һәм сленгтан башка ул үле телгә әвереләчәк. Челтәрдәге телне эмоциональ төсмер керткән чаралардан чистартудан файда юк, бары тик текстны әдәпсезлек дәрәҗәсенә төшермәскә кирәк.

Нәтиҗә чыгарып әйткәндә, Интернетның телләргә, шул исәптән Татнетның татар теленә тәэсире күп яклардан күренә, ләкин системалы категорияләргә барыбер кагылмый.

Телдә барган әлеге яңартулар Интернетта аралашуның аерылгысыз бер өлеше буларак күзалланалар. Алар телнең графика, лексика, морфология һәм сүз ясалышы, синтаксис, стилистика һәм сөйләм культурасы тармакларына кагылалар.

Интернеттагы телнең төп реалийлары дип түбәндәгеләрне атарга мөмкин: сөйләмә телнең язуда беркетелүе, «язмача тыңлаучы» һәм «язмача сөйләүче» кебек төшенчәләрнең кертелүе, эпистоляр жанрның тергезелүе, вербаль булмаган аралашу максаты белән пиктографик язу элементларын куллану һ.б.

Ләкин иң аермалы үзенчәлекләр лексик яктан – лексик берәмлекләрнең мөнәсәбәтендә һәм кулланылышында күренә. Телдә үзенең тел сыйфатлары һәм социокультур характеристикаларга ия махсус лексик система формалаша. Таныш сүзләр куллану ышаныч атмосферасы һәм иреклек эффекты тудыра, күләмле аудитория белән элемтә урнаштырырга һәм катлаулы техник төшенчәләрне кулланучыга якынайтырга ярдәм итә. Компьютер белән Интернетка бәйле төшенчәләрнең күбесе бай сурәтле метафоралар ярдәмендә белдерелә. Шулай ук Интернет лексикасы өчен төрле стиль элементларын берләштерү, сөйләмә сүз һәм әйләнмәләрне, структур төрлелеккә ия булган фразеологизмнарны, тел уены элементларын, сурәтләнгән күренешкә бәя биргән коннотатив сүз һәм сүзтезмәләрне куллану хас.

Интернет теле сөйләмнең язма формасы белән күбрәк охшашлык күрсәтсә, чатларда кулланылган тел аннан кискен аерылып тора. Виртуаль дөньялар һәм электрон хатлар исә алар арасындагы урынны алып торалар.
Әлеге даирәдә кулланылган телдә язма сөйләм кагыйдәләренең барлык катламнарында бозыла алуы күзәтелә. Мәсәлән:

1. Лексик катламда:

а) слэнг гыйбарәләрен куллану;

б) аббревиатура һәм акронимнар аралашу дәвамында вакыт һәм көчне экономияләү өчен, билгеле бер төркемгә карау маркеры буларак, кыскартылган форма эчендә берәр вульгар элементны яшерү яки мәгълүматны шифрлау максатыннан чыгып күпләп кулланa;

в) үзенчәлекле сүз ясау процесслары урын ала, ләкин алар барыбер әдәби телдә кабул ителгән модельләргә – аффиксация, сүз кушу, конверсия, аббревиация ысулларына таянып алып барыла.

2. Синтаксис һәм пунктуация катламында:

а) Интернет текстларында пунктуация ягыннан аграмматизм тенденциясе, ягъни әдәби тел таләпләренә каршы чыгу өстенлек алып тора, тыныш билгеләрен куллану еш кына кешегә бәйле булып кала.

б) Синтаксис дәрәҗәсендәге үзенчәлекләр кулланучы сөйләмендә элептик (кыскартылма) җөмләләрне һәм эмфатик кoструкцияләрне күпләп куллануда күзәтелә.

3. Грамматик катламдагы үзгәрешләр иң әз күләмдә күренә. Мәсәлән, фигыльләрнең редупликациясе чатларда очрап тора, ләкин әлеге феноменны дәвамлы дип санап булмый. Бу очракларда ике тапкыр кабатланган фигыльләр канәгатьлек яки кайгы, сарказм яки күңелсезләнү кебек хис-кичерешләрне белдерү өчен яки бары тик җөмләнең тәмамланганын күрсәтү өчен кулланыла.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, җәмгыять үсеше белән бергә яңа предмет һәм күренешләр барлыкка килә, алар яңа сүз һәм яңа мәгънәләрдә чагыла башлыйлар. Интернетның килеп чыгуы телнең яңа куллану даирәсен тудыра, челтәр теле яки электрон тел оеша. Яшәеше дәвамында әлеге телнең аермалы лингвистик үзенчәлекләре урнашып бетә, шулар арасында иң әһәмиятлесе булып лексик як санала. Ләкин Интернет телен өйрәнү, аеруча татар теленең яңа куллану өлкәсендә үзен ни рәвешле тотуын тикшерү әле башлангыч этапта гына, шуңа күрә бу мәсьәләдә телчеләр өчен күптөрле мөмкинлекләр ачык.